**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Яңа Шашы авыл җирлеге Яңа Шашы торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

"10" ноябрь 2022 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Яңа Шашы торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Яңа Шашы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Яңа Шашы авылында янгын пирсы җайланмасы эшләү (материаллар сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
2) Яңа Шашы авылы территориясен чистарту, агачлар һәм куакларны кисү;

3. 2022 елдагы экономияләнгән үзара салым акчасын, Яңа Шашы авылында янгын пирсы җайланмасы әшләүгә (материаллар сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү) юнәлтергә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Яңа Шашы авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Яңа Шашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Яңа Шашы авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.